**КАРАР**

**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлеге Урта Камышлы авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**15 ноябрь 2022 ел** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2022 елның 15 ноябрендә узган: «Урта Камышлы авыл җирлегенең Урта Камышлы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2023 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1. Су белән тәэмин итү чыганакларына норматив таләпләрне тәэмин итү буенча эшләр үткәрү;
2. Урта Камышлы торак пункты чикләрендә авыл эчендәге юлларны ремонтлау;
3. Зират коймаларын ремонтлау һәм карап тоту;
4. Урам утларын ремонтлау;
5. Иҗтимагый киңлекне төзекләндерү;
6. Янгынга каршы куркынычсызлыкның норматив таләпләрен тәэмин итү буенча эшләр үткәрү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

җыенда катнашучы сайлау хокукына ия булган гражданнар исемлегенә 450 кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә 283 кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 247 кеше тавыш бирде;
«ЮК» позициясе өчен җыенның 36 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлеге Урта Камышлы авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Урта Камышлы авыл җирлегенең Урта Камышлы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2023 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Су белән тәэмин итү чыганакларына норматив таләпләрне тәэмин итү буенча эшләр үткәрү;
- Урта Камышлы торак пункты чикләрендә авыл эчендәге юлларны ремонтлау;
- Коймаларны ремонтлау;
- Урам утларын ремонтлау;
- Иҗтимагый киңлекне төзекләндерү;
- Янгынга каршы куркынычсызлыкның норматив таләпләрен тәэмин итү буенча эшләр үткәрү мәсьәләсе буенча карарны танырга.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Урта Камышлы авыл җирлеге Урта Камышлы авылы мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.
4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Урта Камышлы авыл җирлеге тарафыннан кабул ителгән әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: В.П. Вафина
Урта Камышлы авыл җирлеге башлыгы: В.П. Вафина